**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** Казан ш. **БОЕРЫК**

06.08.2024 865-п

«Энергетик» ҖЧҖ су алу
корылмасының санитар саклык
зоналары булудан туктау турында

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 06.07.2005 ел, № 325 карары, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүрештә су белән тәэмин итү чыганакларының санитар саклык зоналарын билгеләү, үзгәртү, эшчәнлеген туктату турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 17.11.2021 ел, № 1251-п боерыгы нигезендә, 2009 елның 25 февралендәге ТАТ 01129 ВЭ серияле җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясен исәпкә алып, боерык бирәм:

1. «Энергетик» ҖЧҖ су алу корылмасының санитар саклык зоналарын туктатырга.
2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Энергетик» ҖЧҖ су алу скважинасының санитар саклык зоналарын билгеләү турында» 27.09.2022 ел, № 868-п боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Хокукый тәэминат бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрүне тәэмин итәргә.
4. Дәүләт теркәвенә алганнан соң, каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге җитәкчесенә әлеге боерык күчермәсен түбәндәгеләргә җибәрергә:

- «Энергетик» ҖЧҖ;
- «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» ФБУ филиалына, – санитар саклык зонасын туктату турындагы белешмәләрне Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен;
- Татарстан Республикасы Казан шәһәре Башкарма комитетына.

Министр А.В. Шадриков